**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлегенең Югары Лашчы авылында гражданнар җыены карары**

6 ноябрь 2020 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлегенең Югары Лашчы авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2021 елда Югары Лашчы авыл җирлегенең Югары Лашчы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукы булган балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 700 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Югары Лашчы авылында юлларны төзекләндерү эшләрен башкаруга юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Югары Лашчы авыл җирлегенең Югары Лашчы авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Югары Лашчы авыл җирлеге башлыгы _________ Г.Х. Усманова

Халык җыены секретаре _________ Л.В. Андреева